Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим лицее бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

“Медицинага беренче адымың ” исемле Республикакүләм конкурска

**Минем табибым иң-иңе... (тормыштан очрак)**

Авторы: Мөслим муниципаль районы

Мөслим лицее бюджет гомуми белем бирү

мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы

**Афзалова Регина Марат кызы**

Фәнни җитәкче: Мөслим лицееның

татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Ситдыйкова Чулпан Индус кызы

тел. 89179361206

Мөслим-2016

**Минем табибым иң-иңе... (тормыштан очрак)**



**Крымова Л.В.**

Хәтерлим әле, миңа 5-6 яшь булгандыр. Яңа елны каршы алырга санаулы сәгатьләр генә калып килә. Шимбә көн булу өстенә бәйрәм! Мине, эчем авыртып, район хастаханәсенә алып килделәр. Хирург, көйләп-җайлап, эчемне тотып-тотып карады да: “Операциягә әзерләгез!” -диде. Мин, куркып, елый башладым, әнием дә борчыла. Ә табибә ханым безне тынычландыра: “Борчылмагыз, барысы да яхшы булачак! Нибары ярты сәгатьлек операция”-, дигәннәре истә. Анестезия биргәннәрен дә аңламаганмын ( нәни бит әле), йокымсырый башлагач, күтәреп кенә каядыр алып киттеләр.

Йокыдан уянганда палатада идем. Бик нык су эчәсем килгәне истә калган. Күзләрне ачасы килә, керфекләремне дә күтәрә алмыйм, күз кабакларым шундый авыр. Су сорыйм – “Ярамый”, диләр. Урыннан торасым килә – тагын ярамый! Әнием миңа операция ясалганын әйткәч кенә, ни булганы аңлашыла башлады. Ә Яңа ел төнендә миңа операция ясаган табибә – хирург көн саен хәлемне белешеп, мине күзәтеп торды. “Ничек хәлләрең, матурым? Хәзер барысы да әйбәт булачак!” дип, кәефемне күтәреп, елмаеп, хәлләремне сорашучы табибым Мөслим районы хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире Лидия Васильевна Крымова булып чыкты.

Ачык йөзле, тәмле телле Лидия Васильевна! Хастаханәгә һәрвакыт елмаеп килеп керә, һәркемне елмаеп сәламли, барысының да исемен белә. Авыруларның сызлануы, борчылуы аның йөзендә чагылыш таба – Лидия Васильевна уйчанлана. Пациентлар үзләрен яхшы хис итсә, аннан да бәхетле

кеше юк кебек, авырулары белән бергә сөенә. Табибымның куллары шифалы. Ул ясаган операцияләр һәрвакыт уңышлы була, диләр.

Лидия Крымованы туган ягым Мөслим районында яхшы беләләр. Аның белән таныш булмаган, аның ярдәме тимәгән кеше, гомумән, юктыр. Һәркем аны хөрмәт итә һәм һәркайсы **Аңа** рәхмәтле.

Лидия Васильевна үзе Горький өлкәсеннән икән. Казан дәүләт медицина институтын, интернатураны тәмамлагач, ул юллама нигезендә Мөслим районына эшкә килә. Берничә елдан аны район үзәк хастаханәсенең хирургия бүлегенә мөдир итеп билгелиләр. Лидия Васильевнаның Мөслимгә килүенә, безнең районда эшләвенә 40 елдан артык вакыт үткән. Шушы вакыт эчендә ул кемнәргә генә ярдәм итмәгән, кемнәргә генә яңа тормыш бүләк итмәгән?! Халык сәламәтлеген саклауга керткән хезмәте өчен 1995 нче елда Лидия Крымовага “Татарстан Республикасының атказанган табибы” исеме бирелә. Мөслим районы халкы соравы буенча 2014 нче елда Сәламәтлек саклау отличнигы Лидия Васильевна “Мөслим районының мактаулы гражданины” дигән зур исемгә лаек булды.

Халык ихтирамын яулау өчен белем, тәҗрибә генә җитмидер. Лидия Васильевна кебек олы йөрәкле, киң күңелле, мәрхәмәтле, ярдәмчел булырга (табиб, миңа калса, нәкъ менә шушы сыйфатларга ия булырга тиеш!) һәм һөнәреңне чын күңелдән яратырга кирәктер. Бу очракта һөнәреңне ярату ул – кешеләрне дә ярату, дигән сүз. Тирә-юнеңдәгеләрнеңнең кем булуына, аның сиңа булган яки үзеңнең аңа карата нинди мөнәсәбәттә булуыңа карамастан, эчкерсез ярдәм итү теләге. Үзең турында, мәшәкатьләрең, проблемаларың турында онытып, аларны читкә куеп, башкаларга ярдәмгә ашыгу. Чын табиблар шундый була, минемчә.

Табиб һөнәре ял-бәйрәмнәрне белми. Тәүлекнең кайсы вакыты булуына карамастан, Гиппократ антына тугры калган табиблар ярдәмгә ашыга. Аларның да мәшәкатьләре чиктән ашкан, якыннары авыр хәлдә булган мизгелләр юк түгелдер. Тик синең ярдәмеңә мохтаҗлар булуын, кемдер авыр хәлдә, яшәү белән үлем арасында чын күңелдән сиңа ышанып ярдәм көтүен белгән табиб, үз мәшәкатьләрен читкә куеп, пациентлары янына ашыга. Аның кулында – кеше гомерләре! Ул аларның һәркайсы өчен җаваплы. Кеше гомерен тагын күпмегәдер озынайта ала икән – ул бәхетле! Пациентларының, аларның якыннарының шат елмайган йөзләрен, рәхмәт һәм хөрмәт тулы күзләрен күрү белән бәхетле! Кешеләргә ярдәм итә алу – бәхет! Ә табиб

һөнәре – иң игелекле һөнәрләрнең берсе. Мин дә мәктәпне тәмамлагач, медицина буенча уку йортына керергә, табиб һөнәрен үзләштерергә хыялланам. Киләчәктә кешеләргә ярдәм итәсем, табиб буласым килә.